ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

2022 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеге турында хисап хакында

2022 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеге турындагы хисапны тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеге турында хисапны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Хисап палатасының нәтиҗәле эшен, шул исәптән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына ачыклана торган җитешсезлекләрне һәм хокук бозуларны булдырмауга һәм профилактикалауга юнәлдерелгән тәкъдимнәр рәвешендә дә, билгеләп үтәргә.

3. Татарстан Республикасы Хисап палатасына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

чит дәүләтләрнең санкция басымы шартларында дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән бюджет акчаларын тотуны тикшереп торырга;

Татарстан Республикасы дәүләт программалары һәм аларга үзгәрешләр кертү проектларына финанс-икътисадый экспертиза үткәрү, программа чараларының максатчан индикаторларына ирешүне анализлау эшен дәвам итәргә;

Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапка, Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше хакындагы хисапка һәм Татарстан Республикасы бюджеты,

Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законнары проектларына, аларны бюджет законнарында билгеләнгән срокларда тапшыруны исәпкә алып, үз вакытында бәяләмәләр әзерләүне тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасының бюджет кредитлары буенча бурыч йөкләмәләрен үз вакытында үтәүне тикшереп торуны, шулай ук Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелгән акчаларны кире кайтаруны тикшереп торуны тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты торышын һәм бюджетара мөнәсәбәтләрнең нәтиҗәлелеген мониторинглауны гамәлгә ашырырга;

Татарстан Республикасында илкүләм проектларны гамәлгә ашыруны һәм илкүләм максатларга ирешүне тикшереп торуны дәвам итәргә;

тикшереп тору чараларын үткәрү барышында Татарстан Республикасы Хисап палатасы ачыклаган җитешсезлекләр һәм хокук бозулар турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Дәүләт Советына квартал саен тапшыру эшен дәвам итәргә;

Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлегенең ачыклыгын, ул әзерли торган материаллардан файдалана алуны тәэмин итү эшен дәвам итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 8 июне
№ 2014-VI ДС